**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 1 сентябрендәге 3035 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 19 июнендәге 2098 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 124 номерлы "Казан шәһәренең муниципаль мәгариф учреждениеләрендә азык-төлек блоклары хезмәткәрләре саны нормативларын раслау хакында"гы карарына үзгәреш кертү турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 мартындагы 869 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 3921 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 563 номерлы, 2022 елның 6 апрелендәге 962 номерлы, 2023 елның 18 гыйнварындагы 110 номерлы, 2023 елның 18 гыйнварындагы 111 номерлы, 2024 елның 9 февралендәге 453 номерлы, 2024 елның 16 сентябрендәге 3906 номерлы, 2024 елның 22 ноябрендәге 4770 номерлы, 2025 елның 27 февралендәге 475 номерлы, 2025 елның 15 апрелендәге 1167 номерлы, 2025 елның 30 маендагы 1639 номерлы, 2025 елның 13 августындагы 2623 номерлы, 2025 елның 10 ноябрендәге 3845 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм

кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. IV бүлекнең 4.3 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, интернаты, мәктәпкәчә бүлекчәсе булган гомуми белем бирү оешмаларының эшчеләрнең «пешекче, пешекче ярдәмчесе, кече пешекче», «ярдәмче эшче» вазифасы буенча гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә һәм «җитештерү мөдире (шеф-пешекче)» яки «ашханә мөдире» вазифалары буенча җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифаларына керүче хезмәткәрләргә хезмәт интенсивлыгы өчен 40, 25 һәм 50 процент күләмендә түләү бирелә»;

1.2. IV бүлекнең 4.3 пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Гомуми белем бирү оешмаларының эшчеләрнең «пешекче, пешекче ярдәмчесе, кече пешекче», «ярдәмче эшче» вазифасы буенча гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә һәм «җитештерү мөдире (шеф-пешекче)» яки «ашханә мөдире» вазифалары буенча җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифаларына керүче хезмәткәрләргә хезмәт интенсивлыгы өчен 60, 40 һәм 85 процент күләмендә түләү бирелә»;

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**